ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Мәдәният турында» Татарстан Республикасы Законының 3 һәм 17 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 65-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан кертелгән «Мәдәният турында» Татарстан Республикасы Законының 3 һәм 17 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 65-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ / АППАРАТ ГОСУДАРСТВЕННОГО СОВЕТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ
ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ

Казан шәһәре,
2025 елның 18 апреле
№ 270-VII ДС

65-7 номерлы проект

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинеты
тарафыннан кертелә

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗАКОНЫ

**«Мәдәният турында» Татарстан Республикасы Законының 3 һәм 17 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында**

**1 статья**

«Мәдәният турында» 1998 елның 3 июлендәге 1705 номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1998, № 7; 2000, № 12 (11) (II өлеш); 2006, № 12 (I өлеш); 2007, № 11; 2009, № 7 – 8 (I өлеш); 2011, № 3; 2012, № 3; 2013, № 12 (I өлеш); 2014, № 6 (II өлеш); 2015, № 3, № 12 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнары җыелмасы, 2018, № 1 (I өлеш), № 54 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2019, № 40 (I өлеш); 2021, № 36 (I өлеш); 2023, № 27 (I өлеш), № 48 (I өлеш), 92 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3 статьяга түбәндәге эчтәлектәге абзацны өстәргә:

«инвалидларны социомәдәни тернәкләндерү һәм абилитацияләү – и нвалидларны (шул исәптән инвалид балаларны) инвалидларны социаль адаптацияләү һәм җәмгыятькә кертеп җибәрү максатларында аларның мәнфәгатьләре һәм сәләтләре нигезендә инвалидларның мәдәни һәм икътисадый ихтыяҗларын канәгатьләндерүне тәэмин итүче иҗади эшчәнлеккә җәлеп итүгә юнәлдерелгән чаралар комплексы.»;

2) 17 статьяда:

а) түбәндәге эчтәлектәге уналтынчы абзацны өстәргә:

«инвалидларны (шул исәптән инвалид балаларны) социомәдәни тернәкләндерү һәм абилитацияләүне оештыру өчен шартлар тудыру»;»;

б) уналтынчы абзацны унҗиденче абзац дип санарга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Мәдәният турында» Татарстан Республикасы Законының 3 һәм 17 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы закон проектына**

# АҢЛАТМА

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 25 декабрендәге 651-ФЗ номерлы Федераль закон белән 1992 елның 9 октябрендәге 3612-I номерлы Россия Федерациясе Законына үзгәрешләр кертелде. «Инвалидларны социомәдәни тернәкләндерү һәм абилитацияләү» төшенчәсе закон нигезендә беркетелде, гражданнарның мәдәни эшчәнлектән, мәдәни кыйммәтләрдән һәм инвалидларны (шул исәптән инвалид балаларны) социомәдәни тернәкләндерүне һәм абилитацияләүне оештыру өчен шартлар тудыру буенча уңайлыклардан файдалана алуын тәэмин итү буенча дәүләт бурычы арттырылды.

Россия Мәдәният министрлыгының «Инвалидларны (шул исәптән инвалид балаларны) социомәдәни тернәкләндерүне һәм абилитацияләүне оештыру өчен шартлар тудыру тәртибен раслау турында» 2024 елның 20 сентябрендәге 1810 номерлы боерыгы белән Россия Федерациясе субъектларының мәдәният өлкәсендәге башкарма органнарының алар базасында инвалидларны социомәдәни тернәкләндерү һәм абилитацияләү гамәлгә ашырыла торган мәдәният оешмаларын берләштерә торган методологик мәйданчыклар төзүгә хокуклары карала торган тиешле тәртип расланды.

Инвалидларны социомәдәни тернәкләндерү һәм абилитацияләү Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре һәм муниципаль учреждениеләре эшчәнлегендә яңа юнәлеш түгел. Татарстан Республикасында инвалидларны комплекслы тернәкләндерү һәм абилитацияләү системасын камилләштерү Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы дәүләт программалары кысаларында үткәрелә. Татарстан Республикасында инвалидларга мәдәни тормышта катнашу, аларны социомәдәни тернәкләндерү, мәдәният өлкәсендә белем алу хокукын гамәлгә ашыру өчен шартлар тудырыла, шулай ук мәдәни кыйммәтләрдән файдалану мөмкинлеге тәэмин ителә, сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән кешеләр өчен инфраструктураны камилләштерү буенча системалы эш алып барыла, белем бирүнең һәм иҗади үсешнең инклюзив программалары кертелә. Татарстан Республикасы дәүләт мәдәният учреждениеләре базасында инклюзив студияләр, лабораторияләр төзелде, республиканың 1896 мәдәни-ял итү учреждениесендә 1452 инклюзив формирование эшли, республиканың балалар сәнгать мәктәпләрендә инвалид балаларны һәм сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән затларны укыту өчен җайлаштырылган 60 гомуми үсеш программасы, инвалидлар өчен җайлаштырылган 32 өстәмә һөнәри әзерлек программасы гамәлгә ашырыла.

«Әкият» балалар үзәге» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе мәйданчыгында аутизм спектры бозылулары һәм башка психик тайпылышлары булган гражданнар өчен методик үзәк төзелде, аның бурычларының берсе – координацияләү һәм Татарстан Республикасының нейропсихик тайпылышлары булган кешеләргә ярдәм күрсәтә торган әйдәп баручы мәйданчыклары белән үзара хезмәттәшлек итү.

Закон проекты югарыда күрсәтелгән федераль закон нигезләмәләрен гамәлгә ашыруга юнәлдерелгән.

**«Мәдәният турында» Татарстан Республикасы Законының 3 һәм 17 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчләрен югалткан дип танылырга, туктатылып торырга, үзгәрешләр кертелергә яки кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары ИСЕМЛЕГЕ**

«Мәдәният турында» Татарстан Республикасы Законының 3 һәм 17 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы законнарын үз көчләрен югалткан дип тануны, туктатып торуны, үзгәрешләр кертүне яки кабул итүне таләп итми.

«Мәдәният турында» Татарстан Республикасы Законының 3 һәм 17 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы мәсьәләләре» 2005 елның 18 августындагы 409 номерлы карарына инвалидларны социомәдәни тернәкләндерү һәм абилитацияләү алар базасында гамәлгә ашырыла торган мәдәният оешмаларын берләштерүче методологик мәйданчыклар булдыру хокукын өстәү өлешендә үзгәрешләр кертү таләп ителә.

**«Мәдәният турында» Татарстан Республикасы Законының 3 һәм 17 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы закон проектын**

# ФИНАНС-ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЛӘҮ

Татарстан Республикасында инвалидларны социомәдәни адаптацияләү чараларын финанслау Татарстан Республикасы дәүләт мәдәният учреждениеләре эшчәнлеген агымдагы финанслау кысаларында, шулай ук:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 елның 30 декабрендәге «2022 – 2030 елларга Татарстан Республикасында инвалидлар өчен объектларның һәм хезмәтләрнең һәркем файдалана алырлык булу күрсәткечләре мәгънәләрен күтәрүгә юнәлдерелгән чаралар планын («юл картасын») раслау турында» 1517 номерлы карары;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 елның 14 ноябрендәге «2022 – 2026 елларга Татарстан Республикасында аутизм спектры бозылулары һәм башка психик тайпылышлары булган кешеләрне комплекслы озата бару концепциясен раслау турында» 1208 номерлы карары нигезендә каралган чаралар кысаларында үткәрелә.

Закон проектын кабул итү Татарстан Республикасы бюджетыннан өстәмә акчалар бүлеп бирүне таләп итмәячәк.